КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
**Республиканское агентство по печати и массовым коммуникациям**
Декабристов ул., 2, г. Казань, 420066
Тел.: (843) 570-31-22, факс: (843) 537-91-04
www.tatmedia.ru, www.tatmedia.tatarstan.ru
e-mail: ra.tatmedia@ tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ
**Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы**
Декабристлар ур., 2, Казан шәһәре, 420066
Тел.: (843) 570-31-22, факс: (843) 537-91-04
www.tatmedia.ru, www.tatmedia.tatarstan.ru
e-mail: ra.tatmedia@ tatar.ru

ПРИКАЗ БОЕРЫК

«19» июль 2017 г. № 34-п

“Татмедиа” Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгында Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының дәүләти гражданлык хезмәткәрләре барлык кешеләр өчен ачык мәгълүматлар урнаштырган “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтлар адреслары һәм (яки) сайтлар сәхифәләре турында мәгълүматларны, шулай ук аларны тәңгәлләштерү мөмкинлеге биргән мәгълүматларны кабул итү, эшкәртү һәм тикшерү тәртибен раслау турында

“Россия Федерациясенең дәүләти гражданлык хезмәте турында” 27 июль, 2004 ел, № 79-ФЗ Федераль законның 20.2 статьясы, “Татарстан Республикасының дәүләти гражданлык хезмәте турында” 16 гыйнвар, 2003 ел, № 3-ЗРТ Татарстан Республикасы Законының 17.2 статьясы нигезендә, боерык бирәм:

1. “Татмедиа” Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгында Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм “Татмедиа” Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының дәүләти гражданлык хезмәткәрләре барлык кешеләр өчен ачык мәгълүматлар урнаштырган “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтлар адреслары һәм (яки) сайтлар сәхифәләре турында мәгълүматларны, шулай ук аларны тәңгәлләштерү мөмкинлеге биргән мәгълүматларны кабул итү, эшкәртү һәм тикшерү тәртибен (кушымта итеп бирелә) расларга.

2. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче А.Р.Зарипов

"Татмедиа" Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесенең 19.07.2017 ел, №34-п боерыгы белән расланды

"Татмедиа" Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгында Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм "Татмедиа" Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының дәүләти гражданлык хезмәткәрләре барлык кешеләр өчен ачык мәгълүматлар урнаштырган "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтлар адреслары һәм (яки) сайтлар сәхифәләре турында мәгълүматларны, шулай ук аларны тәңгәлләштерү мөмкинлеге биргән мәгълүматларны кабул итү, эшкәртү һәм тикшерү тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. "Татмедиа" Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгында (алга таба - Агентлык) Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм Агентлыкның дәүләти гражданлык хезмәткәрләре барлык кешеләр өчен ачык мәгълүматлар урнаштырган "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтлар адреслары һәм (яки) сайтлар сәхифәләре турында мәгълүматларны, шулай ук аларны тәңгәлләштерү мөмкинлеге биргән мәгълүматларны кабул итү, эшкәртү һәм тикшерү тәртибе (алга таба – Тәртип) билгели:

Агентлыкта Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның (алга таба - гражданин) һәм Агентлыкның дәүләти гражданлык хезмәткәрләренең (алга таба – гражданлык хезмәткәре) барлык кешеләр өчен ачык мәгълүматлар урнаштырган "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтлар адреслары һәм (яки) сайтлар сәхифәләре турында мәгълүматларны, шулай ук аларны тәңгәлләштерү мөмкинлеге биргән мәгълүматларны (алга таба – Сайтлар турында мәгълүматлар, «Интернет» челтәре) тапшыру кагыйдәләрен;

Сайтлар турында мәгълүматлар кабул итү һәм эшкәртү тәртибен;

Сайтлар турында мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү тәртибен.

2. "Мәгълүмат, мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүматны саклау турында" 27 июль, 2006 ел, № 149-ФЗ Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлеше нигезендә, барлык кешеләр өчен ачык мәгълүмат төшенчәсе танышу чикләнелмәгән гомум мәгълүм мәгълүматларны һәм башка мәгълүматларны аңлата. Шул ук вакытта мәгълүмат белән танышуда чикләүнең булмавы, гражданлык хезмәткәре яки гражданин ризалыгыннан башка гына,

урнаштырылган мәгълүматны затларның чикләнелмәгән даирәсенең комачаулыксыз алу һәм үз теләгенә карап файдалану мөмкинлеген күздә тота.

3. Гражданлык хезмәткәренең яки гражданинның шәхесен тәңгәлләштерү мөмкинлеге бирүче мәгълүматлар сыйфатында түбәндәге мәгълүматлар җыелмасы яки шул мәгълүматларның берсе булырга мөмкин: фамилиясе һәм исеме, фотосурәте, хезмәт итү урыны.

## II. Сайтлар турында мәгълүматларны кабул итү һәм эшкәртү тәртибе

4. Сайтлар турында мәгълүматларны тапшыра:

гражданин – Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенә (алга таба – гражданлык хезмәте) кергәндә – гражданлык хезмәтенә керү елына кадәрге өч календарь елы өчен;

гражданлык хезмәткәре – ел саен, хисап елыннан соң килүче елның 1 апреленнән дә соңга калмыйча – алдагы календарь елы өчен.

5. Сайтлар турында мәгълүматлар гражданнар һәм гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән формада (алга таба – Форма) тапшырыла.

6. Гражданлык хезмәткәренең вазыйфаи бурычларын үтәү кысаларында урнаштырылган очракта, барлык кешеләр өчен ачык мәгълүмат Формада чагылдырылмый.

7. Тутырылган форма гражданлык хезмәткәре яки гражданин тарафыннан Агентлык җитәкчесе боерыгы нигезендә Сайтлар турында мәгълүматлар эшкәртүгә җаваплы итеп билгеләнгән кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге хезмәткәренә (алга таба – җаваплы зат) тапшырыла.

8. Җаваплы зат Форманы алган көнне Форманың тулы итеп тутырылу-тутырылмавын, “Интернет” челтәреннән файдаланып, анда күрсәтелгән мәгълүматларның дөреслеген тикшерә, шәхси имзасын куя, бу Тәртип нигезендәге форма буенча журналга мәгълүматлар кертә.

9. Кайбер юллары тутырылмый калган Форма кабул итеп алынмый.

10. Гражданин тарафыннан тапшырылган Формада дөрес булмаган мәгълүматлар ачыкланган очракта, кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге аңа гражданлык хезмәте вазыйфасына билгеләүдән баш тарту турында кичекмәстән хәбәр итә.

11. Сайтлар турында мәгълүматлар җаваплы зат тарафыннан гражданлык хезмәткәрләренең “Татарстан Республикасында дәүләти гражданлык хезмәте һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасы” дәүләт мәгълүмат системасындагы шәхси карточкаларына кертелә.

12. Гражданлык хезмәткәрләре һәм гражданнар тарафыннан тапшырылган формалар Татарстан Республикасы кадрлар бүлегендә биш ел дәвамында саклана, шуннан соң алар Агентлыкта персональ мәгълүматларны эшкәртү кагыйдәләре нигезендә юкка чыгарылырга тиеш.

## III. Сайтлар турында мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү тәртибе

13. Гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан тапшырылган Сайтлар турында мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү Агентлык җитәкчесе (җитәкче вазыйфаларын башкаручы зат) (алга таба - җитәкче) боерыгы нигезендә хәл ителә.

14. Тикшерүгә нигез булып түбәндәгеләр тарафыннан язмача рәвештә тапшырылган мәгълүмат тора:

хокук саклау органнары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм аларның вазыйфаи затлары;

даими эшләүче, сәяси партияләр булып тормаучы башка гомумроссия, төбәкара һәм төбәк иҗтимагый берләшмәләре законы нигезендә теркәлгән сәяси партияләрнең җитәкче органнары;

Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы;

гомумроссия һәм республика массакүләм мәгълүмат чаралары тарафыннан тапшырылган.

15. Җаваплы зат, тикшерү үткәрү турында боерык басылып чыкканнан соң ике эш көне эчендә, гражданлык хезмәткәренә үзенә карата тикшерүнең башлануы турында язмача хәбәр итә.

16. Җаваплы зат гражданлык хезмәткәре тарафыннан тапшырылган Сайтлар турында мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын “Интернет” челтәрендә гражданлык хезмәткәре урнаштырган барлык кешеләр өчен ачык мәгълүматны эзләп табу һәм әлеге мәгълүматның электрон күчермәләрен (скриншотлар) булдыру юлы белән тикшерә.

17. Гражданлык хезмәткәре тикшерү барышында һәм тикшерү нәтиҗәләре буенча язмача рәвештә аңлатмалар бирүгә, өстәмә материаллар тапшыруга хокуклы.

18. Бу Тәртипнең 17 пунктында күрсәтелгән аңлатмалар тикшерү материалларына теркәп куела.

19. Тикшерү материаллары һәм тикшерү барышында тупланган мәгълүматлар җитәкчегә тикшерү үткәрү турында боерык басылып чыкканнан соң 10 эш көненнән дә артмаган срокта тапшырыла.

20. Җитәкче тикшерү нәтиҗәләре буенча 5 көн эчендә карар кабул итә:

гражданлык хезмәткәренә карата юридик җаваплылык чараларын куллануга нигезләрнең булмавы турында;

гражданлык хезмәткәренә карата юридик җаваплылык чараларын куллану турында;

хокук бозу, җинаять, экстремистлык эшчәнлегендә катнашу билгеләре булганда, тикшерү материалларын тиешле компетенциядәге дәүләт органнарына җибәрү турында.

21. Җаваплы зат җитәкче тарафыннан кабул ителгән карар турында ике эш көне эчендә үзенә карата тикшерү үткәрелгән гражданлык хезмәткәренә язмача хәбәр итә.

22. Җитәкченең язмача ризалыгы белән, Сайтлар турында мәгълүматлар

бу хакта бер үк вакытта үзенә карата тикшерү үткәрелгән гражданлык хезмәткәренә хәбәр итеп, тикшерү үткәрүгә нигез булган мәгълүмат тапшырган хокук саклау органнарына, даими эшләүче, сәяси партияләр булып тормаучы башка гомумроссия, төбәкара һәм төбәк иҗтимагый берләшмәләре законы нигезендә теркәлгән сәяси партияләрнең җитәкче органнарына, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына, гомумроссия һәм республика массакүләм мәгълүмат чараларына, персональ мәгълүматлар һәм дәүләт сере турында Россия Федерациясе законнарын үтәү нигезендә, тапшырылырга мөмкин.

23. Тикшерү материаллары тикшерү тәмамланганнан соң өч ел эчендә Министрлыкның кадрлар бүлегендә саклана, шуннан соң архивка тапшырыла.

## IV. Сайтлар турында мәгълүматлар тапшырмаган өчен җаваплылык

24. Гражданин Сайтлар турында мәгълүматлар тапшырмаган очракта гражданлык хезмәтенә кабул ителә алмый, ә гражданлык хезмәткәре гражданлык хезмәтендә эшли алмый.

25. Гражданлык хезмәткәренең Сайтлар турында мәгълүматлар тапшырмавы гражданлык хезмәтеннән җибәрүгә китерә торган хокук бозу булып тора.

“Татмедиа” Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесенең 19.07.2017 ел, №34-п боерыгы белән расланган Тәртипкә кушымта

“Татмедиа” Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгында Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм “Татмедиа” Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының дәүләти гражданлык хезмәткәрләре барлык кешеләр өчен ачык мәгълүматлар урнаштырган “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтлар адреслары һәм (яки) сайтлар сәхифәләре турында мәгълүматларны, шулай ук аларны тәңгәлләштерү мөмкинлеге биргән мәгълүматларны кабул итү, эшкәртү һәм тикшерү

ЖУРНАЛЫ

| № п/п | Форманы тапшыру/кабул итү датасы | Форманы тапшыручының ФИО | Форманы тапшыручының вазыйфасы (гражданин дәгъва кыла торган вазыйфа) | Форманы тапшыручының имзасы (яки форма почта аша алынганда – керү №) | Форманы кабул иткән затның ФИО | Форманы кабул иткән затның имзасы | Тикшерү турында мәгълүмат (боерык реквизитлары, тикшерү нәтиҗәсе) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |